КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 24 ноябрь г.Казань № 903

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина чаралары һәм башка чаралар запасларын оештыру турында» 2014 ел, 6 февраль, 65 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән халыкны һәм территорияләрне саклау турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 28 декабрь, ФЗ-404 нче Федераль законны һәм «Гражданнар оборонасы турында» Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина чаралары һәм башка чаралар запасларын оештыру турында» 2014 ел, 6 февраль, 65 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасы максатларында запаслар номенклатурасын һәм күләмнәрен, 20172 елның 23 маенда Россия Федерациясенең Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгы тарафыннан расланган Гражданнар оборонасы максатларында оештырыла торган, федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар туплый торган матди-техник, азык-төлек, медицина чаралары һәм башка чаралар запаслары номенклатурасын һәм күләмнәрен билгеләү буенча 2-4-71-24-11 нче методик тәкъдимнамәләр нигезләмәләрен һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының «Штаттан тыш һәлакәттән коткару

формированиеләрен оештыру тәртибен раслау турында» 2005 ел, 23 декабрь, 999 нчы һәм «Гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр оештыруның бертип тәртибен раслау турында» 2014 ел, 18 декабрь, 701 нче боерыкларын исәпкә алып, штаттан тыш һәлакәттән коткару формированиеләрен, гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләрне һәм коткару хезмәтләрен җиһазландыру нормаларын расларга»;

3 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасы максатларында запаслар номенклатурасын һәм күләмнәрен, 20172 елның 23 маенда Россия Федерациясенең Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгы тарафыннан расланган Гражданнар оборонасы максатларында оештырыла торган, федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар туплый торган матди-техник, азык-төлек, медицина чаралары һәм башка чаралар запаслары номенклатурасын һәм күләмнәрен билгеләү буенча 2-4-71-24-11 нче методик тәкъдимнамәләр нигезләмәләрен һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының «Штаттан тыш һәлакәттән коткару формированиеләрен оештыру тәртибен раслау турында» 2005 ел, 23 декабрь, 999 нчы һәм «Гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр оештыруның бертип тәртибен раслау турында» 2014 ел, 18 декабрь, 701 нче боерыкларын исәпкә алып, штаттан тыш һәлакәттән коткару формированиеләрен, гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләрне һәм коткару хезмәтләрен җиһазландыру нормаларын раслауны».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин